**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«27» 10 2021 ел Яр Чаллы № 3785

«2021 елга ведомство карамагындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешенә тикшерүләр үткәрү нигезләмәсен һәм еллык планын раслау турында» карарга үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле турында» 2009 елның 27 ноябрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – 100-ТРЗ номерлы Закон) 4 статьясы 3 пункты нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 елга ведомство карамагындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм башка норматив хокукый актларның үтәлешенә тикшерүләр үткәрү нигезләмәсен һәм еллык планын раслау турында» 2021 елның 23 мартындагы 866 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2021 елга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә тикшерүләр үткәрү планын 2 кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә

1.2. Комиссия составыннан чыгарырга:

- Н.С. Габдуллинны;
- Г.И.Хәдиеваны;

1.3. Комиссия составына кертергә:

- А.З. Сабировны – «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы;
- С.С. Колычеваны – «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ кадрлар буенча баш белгече.

2. Әлеге карарны муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның ___ 22-10 ___ 3785 номерлы карарына кушымта

**2021 елга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә тикшерүләр үткәрү планы**

**Тикшерүләр үткәрү максаты:** 2021 елга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле.

| № | Ведомство буйсынуындагы оешманың исеме | Ведомство буйсынуындагы оешманың урнашу урыны | Тикшерү үткәрүнең формасы (документар яки күчмә) | Планлы тикшерү үткәрү чоры | Тикшерү үткәрү срогы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ | Тукай муниципаль районы, Бәтке авылы, Үзәк ур., 43 й. | Документар | 2021 елның IV кварталы | 20 эш көне |
| 2 | «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ | Тукай муниципаль районы, Биклән авылы, Мәгариф ур., 1б й. | Документар | 2021 елның IV кварталы | 20 эш көне |

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27.10
2785 номерлы карарына 3 кушымта

**Ведомство контроле буенча чаралар үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге**

**Комиссия рәисе:**

Хәбибуллин А.Р. – Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе;

**Комиссия әгъзалары:**

1. Бузина Н.К. – Тукай муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы;
2. Сабиров А.З. – «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы;
3. Мадярова Д.Ә. – төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге баш белгече;
4. Гыйлаев Ф.М. – координация советы рәисе, АПК хезмәткәрләре профсоюз комитетының Тукай районы комитеты рәисе;
5. Колычева С.С. – «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ кадрлар буенча баш белгече;
6. Муленкова В.Р. – «Тукай муниципаль районы бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе;
7. Рафинова Л.В. – «Яр Чаллы шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Тукай районы филиалы мөдире;
8. Сабирҗанов Г.Г. – Тукай үзәк район хастаханәсенең баш табибы.